№ 9 (1136), 25 февраль 2012 ел

очраган авырлыклар белән көрәшү теләге һәм тотышы буларак кабул ителергә тиеш. Чөнки *«Аллаһы сабыр итүчеләрне, чыдамнарны сөя»* («Гыймран» сүрәсе, 146 нчы аять).

Тәвәккәл белән бәйле тагын бер кыйммәт - өметне өзмәү. Аллаһы өметсезлеккә бирелүне тыйган. Хәлләребез, эшләребез без теләгәнчә бармаганда да, нәтиҗәнең яхшы булачагына өметләнү киңәш ителгән. Кайчак безнең өчен начар булып күренгән кайбер әйберләрнең безнең өчен яхшы була алуы аңлатылган. Яхшылык һәм начарлыкның Аллаһыдан булуын аңлап, кабул итеп, өметебезне югалтмау киңәш ителгән.

Күрүебезчә, Аллаһы колларының самими рәвештә, көче җиткән кадәр эшләүләрен, тырышуларын тели, нәтиҗәсе нинди генә булуга карамастан, бу тырышлыкларның җавапсыз калмаячагын белдереп, колларын ялкаулык һәм өметсезлеккә бирелүдән саклауны максат итеп куя. «Аллаһы теләгәнчә булыр» дип, бернәрсә эшләмәүче, көч сарыф итмәүче кешеләрнең утырган җирдән яхшылыкка, уңышка ирешүләре мөмкин түгел. Эшләребезне дөрес, тәртипле рәвештә, сабырлык күрсәтеп башкаруны дәвам итеп, Аллаһының ярдәменә ышануыбыз зарур.

**Рәмзия ӘГӘ.**

*(“Иман” газетасыннан)*

# Үз-үзебезгә дошман булмыйк!

Тәмәке тарту - зарарлы гадәтләрнең аеруча киң таралганы. Ул кешенең сәламәтлеген какшата, аның физик мөмкинлекләрен киметә. Шуңа карамастан, соңгы вакытта бу гадәт бик киң җәелде. Мәсәлән, бүгенге көндә ирләрнең өчтән икесе, хатын-кызларның өчтән бере һәм байтак яшүсмерләр тарта.

Тәмәкене беренче булып Мексикада майя индеецлары куллана башлый. Дини йолалар үтәгәндә алар аның яфрагын яндыралар, ә төтенен махсус торбалар аша эчкә суыралар. Аурупада беренче сигараны Колумб экспедициясендә катнашкан матрос Родриго де Херес тарта. Франциягә тәмәкене Франция илчесе Жан Нико алып кайта. Тәмәкенең актив матдәсен әнә шуның хөрмәтенә «никотин» дип атыйлар. Франциядән тәмәке Аурупаның башка илләренә дә күчә. Безнең көннәрдә иң киң таралган ысул - сигарет тарту.

Кеше организмы никотинга бик сизгер. Үтерерлек дозасы (60 мг) 5 - 10 сигарет яки бер сигарада була. Ләкин тәмәке тартканда никотинның күп өлеше янып бетә, бер өлеше төпчектә кала. Шунлыктан бер сигареттан организмга 1-2 миллиграмм, ә бер сигарадан 10 миллиграмм гына никотин эләгә.

Кеше организмына тәмәкенең тискәре йогынтысы тартылган сигаретлар санына гына бәйләнмәгән. Тәмәке тарту сәламәтләргә караганда авыруларга, олыларга караганда балаларга, ирләргә караганда хатын-кызга күбрәк зарар китерә. Ашыгып суырып, ачкарынга тарту бик зарарлы. Бу очракта никотин ашказаны-эчәк юлларын ярсыта.

Тәмәкенең кешегә китерә торган зыяны төтенне ни дәрәҗәдә эчкә тирән суыруга да бәйләнгән. Үпкәләренә төтен кертүче кеше никотин һәм башка нәрсәләрне дә йота. Мәсәлән, цианик водороды, сумала, бензол.

Тәмәке тартмаган кеше беренче тапкыр аны авызына алгач, тартучы кеше чамасын онытып җибәрсә, никотин белән агулануы мөмкин. Мондый агулану тәмәке тартмаучы өчен бигрәк тә хәвефле. Алар тәмәке төтене тулы бүлмәдә торсалар, үзләрен начар хис итә башлыйлар. Беренче чиратта балалар һәм йөкле хатыннар шулай була.

Ашказаны һәм баш авырту, төс китү, тирләү, күңел болгану, баш әйләнү - агулану билгеләре. Соңрак авыртулар көчәя, костыра башлый. Көчле агулану күрү һәм ишетүне боза, һушны җибәрә, күзән җыеруга, кул-аякларның сизмәвенә китерә.

Зыян күрүчегә вакытында ярдәм күрсәтелмәсә яки никотин дозасы артык зур булса, кешенең үлүе дә ихтимал.

Озак вакыт күп итеп тәмәке тарту никотин белән даими агулануга китерә. Моның нәтиҗәсе - йокысызлык, игътибар, эшкә сәләт кимү, ашкайнатуның бозылуы, тәм һәм ис сизмәү. Соңрак йөрәк һәм кан тамырлары авырта башлый, ирләрнең җенси дәрте сүнә, мәнидәге орлык саны кими, хатыннарның күрем циклы бозыла. Вакытыннан элек бала табу, бала төшү ихтимал. Тәнне тимгел басуы да мөмкин.

Тәмәке тартучылар бронх авыруларыннан интегәләр: ютәл барлыкка килә һәм сулыш юллары кысыла, иммунитет зәгыйфьләнә. Статистика күрсәткәнчә, тәмәке тартучылар үпкә авыруларыннан тартмаучыларга караганда ешрак үлә. Канцероген матдәләр тәмәке тарту аркасында йомшаган лайлалы ярыда таза ярыга караганда катырак активлаша. Шунлыктан аны берничә ел никотин белән ярсыту ахыр чиктә яман шешкә китерә. Шуның аркасында тәмәке тартучыларның үпкә һәм өске тын юллары рагы белән авырып китү куркынычы бик зур. Тәмәке тарту нәтиҗәсендә кешенең үпкәләре генә түгел, башка әгъзалары да авырта башлый, ашкайнату начарая, йөрәк-кан тамыры авырулары барлыкка килә, бигрәк тә аяк кан тамырлары нык зарарлана.

Статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, тәмәке тартучы 50-56 яшьләрдәге кешеләр йөрәк-кан тамыры авыруларыннан һәм атеросклероздан тартмаучыларга караганда ике тапкыр күбрәк үлә. Тартмау-





җәннәткә керерсең”, дип җавап биргән. Ягъни без күпме фарыз гамәлләрне үтибез, шулкадәр Аллаһы Тәгаләгә якынаябыз. Шул фарызларның берсе — намаз. Тик дөнья мәшәкатьләре аркасында намазларыбыз укылмыйча калырга мөмкин. Шуңа күрә аларны соңрак, вакыт булгач, укысаң, хәерле була. Чөнки күпме каза намазы кылабыз, Аллаһы Тәгалә безне шулкадәр яратыр, Аңа якын булырбыз.

**- Мин 92 яшьлек икенче группа инвалиды. Һәр елны ураза тотам. Тик кичен ятканда күзләремә дару салам. Минем уразам кабул буламы икән? Ярамаса, уразага кергәч, мин дару салмас идем.**

**Хөсәен КӘРИМОВ.**

Похвистнево шәһәре.

- Ураза тотканда, авыз ачканнан соң, кичен безгә ашарга-эчәргә дә, дару кабул итәргә дә, укол кадарга да рөхсәт ителә. Ә инде 92 яшьлек инвалидның хәле шулкадәр авыр икән, ул көндез дару салса да, уразасы бозылмый. Әгәр инде кеше нык авыру сәбәпле ураза тота алмаса, ул бер көн тотмаган уразасы өчен бер ятимне, мескенне ашатырга тиеш. Ашата алмаса, булдырган кадәр садака бирергә кирәк.

**- Самарада кояш ничәдә кыйбла юнәлешендә булуын язсагыз, бу барыбызга да файдалы булыр иде. Шулай ук компас белән ничек кыйбланы дөрес итеп табарга кирәклеген дә тәфсилләп аңлатсагызчы.**

**Похвистнево районының**
**Гали авылы халкы.**

- Самарада кояш кыйбла юнәлешендә зәвәл вакытында була. Ә инде сәгатенә килсәк, ул һәр көнне төрлечә була. Моны намаз вакытлары таблицасыннан карарга мөмкин.

Ә компас белән тапканда аны көньякка таба куябыз, шул якта кыйбла була. Компас булмаган очракта кояш сул ягыбыздан чыгып, уң ягыбызга бата икән, алдыбызда кыйбла була.

**Сорауларга җавапларны Самара Җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы Наил хәзрәт СӨЛӘЙМАНОВ бирде.**

# Никах һәм гаилә тормышы

*Гаилә – исламның иң зур байлыгы, ә гаилә кору – ярты иман. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әй, яшьләр! Әгәр сез өйләнер хәлдә (матди, физик, рухый һәм әхлакый) икән, сез бу эшне башкарырга тиеш.*

*Ә кем өйләнерлек хәлдә түгел, ураза тотсын, чөнки ураза аңа сак була», – дигән.*

## НИКАХ

Гаилә коруның иң мөһим этабы – никах. Никахның билгеле бер тәртибе бар:

- шаһитлар (ике ир-ат яки бер ир, ике хатын-кыз), Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә җәмгыять каршында бу ике яшьнең ир-хатын булуларын белүче.

Никах хакында туганнарга, дусларга хәбәр итү кирәк;

- әти-әни фатыйхасы. Әгәр әти-әни юк икән, кызның иң якын туганы ризалыгы;

- ир-хатынның тигезлеге (матди) яки ир хатыннан социаль статусы һәм матди хәле буенча түбән булмаска тиеш. Әгәр түбән булса, гаилә белән идарә итү хатын-кыз кулына күчеп, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә тудырган гармония җимерелә. Әмма, имам Мәлик фикеренчә, билгеле, акыллы ир-ат теләсә нинди бай хатын-кызга өйләнергә мөмкин, чөнки ул дини һәм дөньяви гыйлеме белән теләсә нинди тормыш мәшәкатендә «дилбегәне» кулында нык тотачак.

- мәһәр яки никах бүләге, бары тик кәләшкә генә бирелә торган бүләк. «Ән-Ниса» сүрәсенең 4 нче аятендә: *«Хатыннарга мәһәрләрен бүләк итеп бирегез. Әгәр алар бирнәләреннән нәрсәне дә булса сезнең файдага аерсалар, аны саулыкка дип ашагыз»,* – диелә. Бу аятьнең асылын хәдисләр белән тулыландырырга мөмкин: *«Бер-берегезгә бүләкләр бирегез, бу мәхәббәтне үстерә генә».*

Өстәвенә, әгәр хатын-кыз ялгыз калып, тормыш йөген ялгыз тартса, мәһәр аңа «башлангыч капитал», «залог» булып тора (ире үлә яки алар аерылыша икән).

## ТУЙ

Туйга туганнарны, дусларны җыеп сыйларга мөмкин. Үзенең сәхабәләренең берсе өйләнүен ишеткәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Бер сарык суйдырып (корбан итеп) булса да, кунаклар дәш»,* – дигән. Әмма матур туй мәҗлесен исерткеч эчемлекләр куеп хәрәм итәргә ярамый.

## ГАИЛӘ

Гаилә тормышында төрле хәлләр булырга мөмкин. Ир кеше һәрвакыт дөрес гамәлдә булырга тиеш. Әгәр хатыны көйсезләнә икән, ир-атка моны мәзәк белән үткәрергә кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хатыннары белән шаяртып аралашкан: *«Сезнең иң тәрбияле һәм иманлыгыз – гаиләгә йомшак, итагатьле булганыгыз»,* – дигән. Ә ирләргә: *«Ирнең иң әйбәте – хатынына яхшы мөгамәләдә булганы»,* – ди. Аның сәхабәсе Гомәр: «Ир кеше гаиләсенә бала кебек йомшак булсын. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә усал һәм мәкерле ирләрне (гаиләсенә карата) яратмый», – ди. Әмма иргә хатын-кызның көен көйләп, ирлек дәрәҗәсен төшерергә ярамый. *«Хатынының колы бәхетле булмас»,* дигән хәдис бар. Әгәр Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә тарафыннан яратылган гаиләдә ир баш рольне башкара алмый икән, гаиләнең асты өскә килә.

Имам әш-Шәфигъ: *«Әгәр көйсез хатыныңны көйләсәң, ул сине түбәнсетәчәк»,* – ди. Ир кешегә бик үк йомшак булу ярамас. Ир авыруга дәва өчен дару язучы табиб кебек булырга тиеш. Әгәр хатыны көчсез икән, ул аңа игътибарлы, ярдәмчел караштa булырга, әгәр хатыны дуамал икән, ул аны вакытында тыярга тиеш.

**(Дәвамы бар)**

**Сәрия ЗАКИРОВА.**

*(«Дин вә йола» газетасыннан)*